**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№7460**
**22.12.2022**

Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 22 декабрендәге
7460 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
«Орион» яшьләр үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе
тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе |
|---|---|---|---|
| I. Мәдәни-массакүләм, тамаша һәм спорт чаралары оештыру буенча хезмәтләр | | | |
| 1 | Театральләштерелгән һәм тематик бәйрәм программасы (көзге бал, Яңа ел, чыгарылыш кичәләре һ.б.) | кеше/сәгать | 300,00 |
| 2 | Конкурслар һәм фестивальләр үткәрү | кеше | 280,00 |
| 3 | «Дискотека» | кеше/сәгать | 100,00 |
| 4 | Театральләштерелгән һәм тематик бәйрәм программасы, күңел ачу уен программасы | кеше/сәгать | 120,00 |
| 5 | Иҗат мастерское | кеше/сәгать | 150,00 |
| 6 | Күңел ачу уен программасы | кеше | 450,00 |
| II. Үстерү хезмәтләре | | | |
| 1 | «Әни белән бергәләп» программасы | 1 дәрес/1 кеше | 190,00 |
| 2 | «Стажерлар мәктәбе» программасы | 1 дәрес/1 кеше | 125,00 |
| 3 | Семинар (тренинг) оештыру һәм үткәрү | кеше/сәгать | 350,00 |
| III. Өстәмә хезмәтләр | | | |
| 1 | Фото, видео аппаратурасын прокатка бирү | сәгать | 350,00 |
| 2 | Костюмнар прокаты | 1 тәүлек | 600,00 |
| 3 | Фото, видео- һәм аудиоязма хезмәтләре | сәгать | 400,00 |
| 4 | Конкурсларда һәм фестивальләрдә катнашу өчен оештыру взносы | кеше | 280 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева